"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы "Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге"

Педагогик совет утырышында каралды һәм кабул ителде
Беркетмә № 1
"13" 09 2013 ел.

ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛДЕ
13.09.2013 приказ № 130
Директор: ОББМБО "Азнакай шәһәре БИҮ"
_________ Р.М Хасанова

# "Әдәби мирас" өстәмә гомуми белем бирү, гомумүсеш программасы

Юнәлеше: туристлык – туган төбәкне өйрәнү
Укучыларның яше: 10 - 15 яшьлекләр өчен
Гамәлгә ашыру вакыты: 4 ел (792 сәгать)

Автор-төзүче:
Ихсанова Эльвира Таһир кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

Азнакай шәһәре, 2017

Эчтәлек

1.Аңлатма язуы_________________________________________3 бит

2.Уку-укыту тематик планы______________________________7 бит

3.Программаның эчтәлеге_______________________________ _9 бит

4. Планлаштырылган нәтиҗәләр__________________________13 бит

5. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары

_____________________________________________________16 бит

6. Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары__ 17 бит

7.Әдәбият исемлеге______________________________________19 бит

## 1 нче бүлек. Аңлатма язуы

“ӘДӘБИ МИРАС” өстәмә гомуми белем бирү, гомум үсеш программасы *түбәндәгеләрне норматив-хокукый документларга нигезләнеп төзелде :*

– Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерык

– РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының “Белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан куллану тәртибен раслау турында” 2017 елның 23 августындагы 816 номерлы боерык»

- 2025 елга кадәр РФнең Тәрбия үсеше стратегиясе;
- 2015-2025 нче еллар өчен ТРда укучыларның Тәрбия үсеше стратегиясе;
- ТРның белем бирү учреждениеләрендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү буенча эшне оештыру стандартлары;
- “Балаларга өстәмә белем бирү күп профильле өстәмә белем оешмаларында өстәмә муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатының яңа редакциядәге модельләштерелгән стандартларын раслау турында” Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 20 нче мартында чыккан № 1465/14 приказы ;
- "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" 29.12.2012 чыккан № 273 - ФЗ федераль законы;
- Балаларга өстәмә белем бирү үсеш концепциясе (4 нче сентябрь 2014 нче елда чыккан, № 1726-р РФ Хөкүмәте карары );
- "СанПиН 2.4.4.3172 -14 "Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында эш оештыру төзелеше, эчтәлеге һәм режимына куела торган санитария-эпидемиология таләпләре " – РФ дәүләт баш санитария табибының 04.07.2014 чыккан 41 нче номерлы карары;
- "Балаларга өстәмә белем бирү программаларына якынча таләпләр” 11.12.2006 нчы елда чыккан Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының №06-1844 хатлары;
- РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 нче елның ноябрендә чыккан “Өстәмә гомумбелем бирү программаларын проектлаштыру буенча методик тәкъдимнәре” .

Программаның юнәлеше – **туристлык – туган төбәкне өйрәнү.**

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала. Программа

түгәрәккә йөрүче укучыларның көче җитәрлек чараларны тормышка ашыруда ярдәм итү, үткәннәр һәм бүгенге белән кызыксыну, туган як тарихын, табигатен, халкын, мәдәниятен, әхлак хәзинәләрен өйрәнүне шарт итеп куя. Баланың үсеш мөһитен дөнья мәдәниятенең һәм милли мәдәниятнең чын кыйммәтләре белән тулыландыру өчен алым һәм технологияләр эзләү, шуның нигезендә рухи яктан бай һәм әхлакый чиста күңелле шәхес формалаштыру актуаль мәсьәлә булып тора. "Әдәби мирас" берләшмәсе – тәрбия эшендә олы хәзинәнең мөһим бер өлеше дияргә була. Халкыбызның үткәне, бүгенгесе, гасырлар буена бөртекләп җыелып килгән акыл һәм рухи байлыгын, сәнгате, мәгърифәте, гореф-гадәтләре, уеннары, әхлак принциплары, тарихи истәлекләре, туган ягыбызның табигате, байлыклары, күренекле шәхесләре, һ.б. үз эченә алып өйрәнү – балаларга аралашу күнекмәләрен формалаштыруга, белемнәрен арттыруга, иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинчелек бирә. Ядкарьләргә кызыксыну уятып, борынгы бабаларыбызның үткән тормышын, буыннар бәйләнеше тарихын өйрәнеп, хәзерге заман тормышы белән чагыштырып аңлату, балалар күңеленең әхлакый, рухи үсешенә зур йогынты ясый. Ә өлкәннәргә карата миһербанлы -шәфкатьле, кечеләргә карата ихтирамлы, табигатькә карата сакчыл булу, туган ягыбызның батыр, легендар шәхесләре белән горурлана белү кебек сыйфатларга да ул шушында, ягъни берләшмәдә ия була.

Әдәби мирас" өйрәнү берләшмәсендә шөгыльләнгән бала:

- үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
- мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый;
- материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;
- эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
- туган як әдәбияты, тарихы буенча белемнәрен арттыра;
- фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;
- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле күренекле шәхесләре белән горурлана.

**Программаның актуальлеге:** Әлеге программа укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте, әдәбият-сәнгате буенча белемнәр формалаштырырга мөмкинлек бирә. Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота. Укучылар үзләре яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен эзләнү – тикшеренү эшләре аша ачыклыйлар; үз халкының рухи байлыгын өйрәнеп, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылалар; туган як белән кызыксынулары аша аңа мәхәббәт, туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән горурлану хисләре тәрбияләнә.

Программаның актуальлеге укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте, әдәбият -сәнгате буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

**Программаның аерылып торучы үзенчәлекләре:** Матур әдәбиятны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый. Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына, үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала. Эзләнү–тикшеренү эшләре аша, калган укучыларга да туган ягыбызның тарихын җиткерү, халкыбызның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате белән кызыксындыруга ирешү.

**Программаның адресаты:** 10-15 яшьлек укучылар, группада беренче уку елында 15 укучы, икенче уку елында 12 укучы, өченче һәм алдагы уку елларында 10 укучы булу яхшы.

**Программаны үзләштерү вакыты, дәресләр үткәрү режимы, периодлылыгы, дәвамлылыгы:** "Әдәби мирас" программасы 4 елга исәпләнә. Беренче елда дәресләр атнага 2 тапкыр, 2 шәр сәгатьтән 15 минутлык тәнәфес белән үткәрелә. Укыту планы буенча 144 сәгать. Икенче, өченче һәм дүртенче елда дәресләр атнага 3 тапкыр, 2 шәр сәгатьтән 15 минутлык тәнәфес белән үткәрелә. Укыту планы буенча 216 сәгать.

**Оештыру үзенчәлекләре:** төрле яшьтәге укучылар.

Дәресләр берләшмәнең барлык катнашучылары белән дә, аерым алынган тема буенча укучылар төркеме белән дә, конкурс эшләрен, тикшеренү эшләрен, проектларны әзерләгәндә индивидуаль консультацияләр рәвешендә дә узарга мөмкин.

Дәресләрне кирәк булганда,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы "Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге" һәм Урманай урта мәктәбе арасында төзелгән челтәрле элемтә турында килешү нигезендә Урманай урта мәктәбе базасында үткәрергә мөмкин.

Укыту формасы: көндезге. Программаны яки аның өлешләрен тормышка ашырганда, электрон укыту, дистанцион белем бирү технологияләрен, практик дәресләр, укучыларның өлгерешен тикшерү өчен агымдагы контроль, арадаш аттестация формаларын кулланырга мөмкин.

**Максат:** укучыларны туган ягыбыз тарихы,табигате, аның күренекле шәхесләре белән тирәнтен таныштыру; укучыларда буыннар бәйләнеше, тарихи ядькарләргә кызыксыну уяту, борынгы бабаларыбызның үткәне белән горурлану хисләре тәрбияләү; иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

Программа түбәндәге **бурычлар**ны үз эченә ала:

*Уку – укыту:*

әдәби мирас һәм аның аша туган тел, дөнья мәдәнияте хәзинәләре, цивилизация казанышларын файдалану мөмкинлегенә ия булу;

төрле мәдәниятләрнең үзенчәлекләрен аңлау өчен нигез хәзерләү һәм аларга хөрмәт тәрбияләү;

рухи, әхлакый, эмоциональ, иҗади, этик һәм танып белү үсешенә тәэсир иткән интеллектуаль һәм социаль үсеш арасындагы бәйләнешне аңлау;

туган як тарихы, табигате, халкы, мәдәнияте турында мәгълүматлар туплау;

үз нәселләренең шәҗәрәләрен һәм гаилә гербын төзү;

туган як тарихына кагылышлы язмалар тупланмасын булдыру, аны тулыландырып тору;
эзтабарлык эшен оештыру методикасын үзләштерү.
*Тәрбияви:*
-укучыларда милли үзаң формалаштыру;
берләшмәгә йөрүче укучыларны туган ягыбыз тарихы, мәдәни мирасы, табигате, аның күренекле шәхесләре белән тирәнтен таныштыру;
укучыларда буыннар бәйләнеше, тарихи ядькарләргә кызыксыну уяту, борынгы бабаларыбызның үткәне белән горурлану хисләре тәрбияләү;
укучыларның танып-белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү; балаларда үз халкына, тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту, үз милләте тарихына, яшәешенә битараф булмаска өйрәтү;
иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.
*Үстерелешле:*
укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;
туган төбәгебезнең истәлекле урыннарына, җөмһүриятебезнең тарихи шәһәрләренә, табигатькә экскурсияләр үткәрү;
мөстәкыйль рәвештә эзләнү – тикшеренү һәм иҗади эшләргә рухландыру;
укучыларда иҗади эшкә омтылыш уяту;
укучылар өчен экскурсияләр оештыру, эзтабарларны төрле конкурсларга әзерләү;
төрле уеннар, экскурсия, кичә - очрашулар уздыру.

## 2 нче бүлек. Укыту- тематик план

### Беренче уку елының укыту- тематик планы

| № | Тема | Сәг. саны | Теория | Практика | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. | 4 | 4 | - | |
| 2. | Мин һәм минем гаиләм | 16 | 6 | 10 | Шәҗәрә төзү |
| 3. | Туган авылым бай тарихлы Урманай | 60 | 21 | 39 | Әңгәмә, практик эш |
| 4. | Авылдаш язучыбыз Гариф Галиев иҗаты | 16 | 8 | 8 | Практик эш – презентация төзү |
| 5. | Татарстан – минем республикам | 48 | 20 | 28 | Интеллектуаль уен - бәйге |
| | **Барысы:** | **144** | **59** | **85** | |

### Икенче уку елының укыту- тематик планы

| № | Тема | Сәг. саны | Теория | Практика | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. | 2 | 2 | - | |
| 2. | Тарих битләрен барлаганда | 50 | 30 | 20 | Әңгәмә |
| 3. | Үткән еллар сәхифәсе | 74 | 44 | 30 | Телдән журнал |
| 4. | Җирле хакимият үткән юл | 36 | 14 | 22 | Әдәби – музыкаль кичә |
| 5. | Авылымның мәгърифәтчелек учаклары | 54 | 22 | 32 | Интеллектуаль уен – бәйге Әңгәмә |
| | **Барысы:** | **216** | **112** | **104** | |

### Өченче уку елының укыту- тематик планы

| № | Тема | Сәг. саны | Теория | Практика | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. | 2 | 2 | - | |
| 2. | Нәселем шәҗәрәсе | 13 | 13 | - | Шәҗәрә төзү |
| 3. | Туган авылым бай | 28 | 28 | 30 | Телдән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | тарихлы Урманай | | | | журнал |
| 4. | Авылдаш язучыбыз Гариф Галиев иҗаты | 22 | 14 | 22 | Әдәби – музыкаль кичә |
| 5. | Татарстан - минем республикам | 20 | 12 | 18 | Интеллектуаль уен – бәйге Әңгәмә |
| | Барысы: | 216 | 112 | 104 | |

**Дүртенче уку елының укыту- тематик планы**

| № | Тема | Сәг. саны | Теория | Практика | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. | 2 | 2 | - | |
| 2. | Гасыр кичкән мәктәбем | 50 | 30 | 20 | Телеграммканал ясау |
| 3. | Урманай урта мәктәбе үткән юл. | 104 | 54 | 50 | Телдән журнал |
| 4. | Данлы укучылар | 36 | 14 | 22 | Әдәби – музыкаль кичә |
| 5. | Мөгаллим профессиясен сайлаган укучыларыбыз | 24 | 22 | 32 | Интеллектуаль уен – бәйге Әңгәмә |
| | **Барысы:** | **216** | **112** | **104** | |

## 3 нче бүлек. Программаның эчтәлеге
## 1 нче уку елы

**Мин һәм минем гаиләм**

**Теория:** Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү. Хатлар ни сөйли? Нәселем шәҗәрәсе. "Шәҗәрәдә гаиләм тарихы". Нәсел агачын төзү үрнәкләре.

**Практика:** Хатлар ни сөйли? Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре. Нәселем традицияләре. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу. Нәсел агачын төзү (үз гаиләң үрнәгендә).

**Туган авылым бай тарихлы Урманай**

**Теория:** Урманай тарихы. Авылымның исеме каян килеп чыккан? Авылымның географик атамалар һәм аларның тарихы. Сугыш чоры балалары. Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында сөйләшү). Шушы яктан, шушы туфрактан без. "Әй Урманай, гүзәл җирем, туган як кынам" - дәрес-конференция.

**Практика:** Авылымның географик атамалар һәм аларның тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу). Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре. Мәктәп музеена экскурсия. Урманай тарихы. Мәдәният йорты музеена экскурсия. Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре (төрле һөнәр ияләре белән очрашу). Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу). Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу). Мәктәпнең элекке укытучылары (Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау). Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу). Алар безнең мәктәптә укыдылар ( Материаллар туплау, стенд төзү). Күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү. Урманайның тарихи урыннары.Телдән журнал. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Республика, район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

**Авылдаш язучыбыз Гариф Галиев иҗаты**

**Теория:** Гариф Галиевнең тормыш юлы белән танышу. Г.Галиевнең иҗатына күзәтү ясау. Телдән журнал. Данлы әдибебез (музей материаллары белән танышу). Г. Галиевнең балалар өчен язган әкиятләре. Г. Галиев әкиятләре. Г. Галиев әкиятләрендә табигать темасы. Г. Галиев "Аю агачлар белән сөйләшә" әкиятендә экология темасы. Әкиятләр дөньясында. Г. Галиев – прозаик. Г.Галиевнең "Курайлы елга" повестендә туган як темасы. Г. Галиев "Истә, һаман да истә" хикәясе. Г. Галиев хикәяләрендә җир көче.

**Практика:** Г. Галиев хикәяләрендә авыл темасы. Г.Галиев әсәрләрендә Урманай авылы тарихы. Г.Галиевнең "Курайлы елга" повестендә географик атамалар. Г.Галиевнең әсәрләрендә районыбыз тарихының чагылышы. Г.Галиев –журналистлык эшчәнлеге. Г.Галиевнең рус һәм алман телендә нәшрият ителгән әсәрләре. Әдәби – музыкаль кичә "Шушы яктан, шушы туфрактан без". Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

**Татарстан – минем Республикам**

**Теория:** Татарстан Республикасы тарихы. Татарстанның символикасы. ТРның географик урыны. Татарстанның табигате. ТР шәһәрләре Республика

шәһәрләре белән таныштыру. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга - чор - дәверләр капкасы. Күренекле шәхесләр: язучылар. Күренекле шәхесләр: шагыйрьләр. Күренекле шәхесләр: җырчылар. Күренекле шәхесләр: артистлар.

**Практика:** Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. “И Казан! Серле Казан!” Башкалабыз Казанга багышланган “Йолдызлы сәгать” уены. Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...). Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе. Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы. “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- “Тамчы-шоу” уены. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

**Укыту-тематик планының эчтәлеге (2 нче уку елы)**

**Тарих битләрен барлаганда**

**Теория:** Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү. Туган җиреңнең тарихын беләсеңме? - Урманай авылы тарихын өйрәнү. Урманай бабай нәселе. Эпиграфик ядкярләр. Тарихи документларның төрләре. Топонимнар фәне нәрсә турында сөйли ? Авыл исеменең килеп чыгышы. Ревизия язмалары.

**Практика:** Авыл кешеләренә сыйфатлама-характеристика язу. Авыл тарихында хуҗалык китабының роле. 1934 елгы хуҗалык китабына күзәтү. Нәселем тарихы тарихи документларда. Тарихи уйланулар. Мәдәният йорты музеена экскурсия.

**Үткән еллар сәхифәсе**

**Теория:** Илебез азатлыгы өчен көрәшүчеләр (Гражданнар сугышы истәлекләре). Бөек Ватан сугышында катнашкан авылым кызлары. Сугыш кырларындагы авылым яугирләре. Балалар керделәр утларга. Җиңү игенчеләре.

**Практика**: Дәһшәтле еллар кайтавазы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу). 2. Дәһшәтле еллар истәлеге. Сугышлы балачак. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Азнакай шәһәренең туган якның өйрәнү музеена сәяхәт. Авылыбызның репрессия корбаннары. Кара шәүлә тантана иткән еллар. Аянычлы еллар хатирәсе. Хәтер яшәсен, нәфрәт дәшмәсен. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

**Җирле хакимият үткән юл**

**Теория:** Дөнья күрке - Урманай. Тарихыбызның серле атавы. Авыл шулай төзекләнде. Авылым оешмалары- яшәеш үзәге.

**Практика**: Авыл хакимиятенең тарихы (музей материаллары белән танышу). Ветераннар оешмасының күренекле вәкилләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу). Һәйкәлләр тарихы. Мәдәният йорты музеена экскурсия. Әдәби – музыкаль кичәгә әзерлек “Күмәк хезмәт еллары”.

**Авылымның мәгърифәт учаклары**

**Теория**: Мәдрәсәдән башланган белем юлы. Совет власте елларында мәктәп тарихы. Ветеран укытучылар. Үзебезнең талантлар. Мәдәният йорты тарихы.

**Практика**: Балалар бакчасы тарихы. Мәктәп тарихына багышланган “Йолдызлы сәгать” уены. Салахова Илмира - авылдаш шагыйрәбез. Туган

төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр. “Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы. “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- “Тамчы-шоу” уены. Туган җир моңы. Сабантуй бәйрәме - милли тантана. Сабантуйлы Урманай. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

**Укыту-тематик планының эчтәлеге (3 нче уку елы)**

***Нәселем шәҗәрәсе***

**Теория:** Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү. Нәселем традицияләре. “Шәҗәрәдә гаиләм тарихы”. Нәсел агачын төзү үрнәкләре

Туган җиреңнең тарихын беләсеңме?

**Практика:** Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу. Нәсел агачын төзү үрнәкләре. Авыл тарихында хуҗалык китабының роле. 1934 елгы хуҗалык китабына күзәтү. Нәселем тарихы тарихи документларда. Тарихи уйланулар. Мәдәният йорты музеена экскурсия.

***Туган авылым бай тарихлы Урманай***

**Теория:** Авылымның исеме каян килеп чыккан ? Авылым кешеләренең культурасы һәм көнкүреше(җырлар,бәетләр)

Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре . Сугыш чоры балалары**.** Сугыш чоры балалары (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу).

**Практика**:Мәктәп музеена экскурсия. Урманай тарихы . Мәдәният йорты музеена экскурсия Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу).Авылымның географик атамалар һәм аларның тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу) Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу). Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында сөйләшү). Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) Мәктәпнең элекке укытучылары ( Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау). Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу). Алар безнең мәктәптә укыдылар ( Материаллар туплау, стенд төзү). Шушы яктан, шушы туфрактан без.

Күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү. Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

***Авылдаш язучыбыз Гариф Галиев иҗаты***

**Теория:** Гариф Галиевнең тормыш юлы белән танышу Г.Галиевнең иҗатына күзәтү ясау. *Телдән журнал.* Данлы әдибебез ( музей материаллары белән танышу) Г. Галиевнең балалар өчен язган әкиятләре. Г. Галиев әкиятләрендә табигать темасы. Г. Галиев “Аю агачлар белән сөйләшә” әкиятендә экология темасы. Г. Галиев –прозаик. Г. Галиев хикәяләрендә җир көче. Г. Галиев хикәяләрендә авыл темасы. Г.Галиев әсәрләрендә Урманай авылы тарихы. Г. Галиев “Истә, һаман да истә” хикәясе. Г.Галиевнең “Курайлы елга” повестендә туган як темасы. Г.Галиевнең “Курайлы елга” повестендә географик атамалар. Г.Галиевнең әсәрләрендә районыбыз тарихының

чагылышы. Г.Галиев –журналистлык эшчәнлеге. Г.Галиевнең рус  һәм алман телендә нәшрият ителгән әсәрләре.
**Практика**: Г.Галиевнең иҗатына күзәтү ясау. *Телдән журнал.* Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау
***Татарстан - минем республикам***
**Теория**: Татарстанның символикасы. ТРның географик урыны. Татарстанның табигате. ТР шәһәрләре. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга - чор - дәверләр капкасы. “И Казан! Серле Казан!” Күренекле шәхесләр: язучылар. Күренекле шәхесләр: җырчылар. Күренекле шәхесләр: артистлар
**Практика**: Республика шәһәрләре белән таныштыру. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. Башкалабыз Казанга багышланган *“Йолдызлы сәгать” уены.* Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...)
Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау
**Укыту-тематик планның эчтәлеге (4 нче уку елы)**
Гасыр кичкән мәктәбем
**Теория:** Үз мәктәбеңнең тарихын беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү. Мәктәп музее ни сөйли?  Фоторәсемнәр аша сәяхәткә. Мәктәп тарихы данлы юл. Мәктәп тарихы тарихи документларда. Тарихи уйланулар. Мәдәният йорты музеена экскурсия.
**Практика:**  Фоторәсемнәр ни сөйли?  Мәктәп тарихы тарихи документларда. Тарихи уйланулар. Мәдәният йорты музеена экскурсия. Телегрммканал төзү
Урманай урта мәктәбе үткән юл.
**Теория:** Мәдрәсәдән башланган юл. 30 еллар тарихы. 40 еллар тарихы. 50 еллар тарихы. 70 еллар тарихы. 80 еллар тарихы. 90 еллар тарихы. 2000 еллар тарихы. 2010 еллар тарихы. 2020 еллар тарихы.
**Практика:** 30 еллар тарихы. 40 еллар тарихы. 50 еллар тарихы. 70 еллар тарихы. 80 еллар тарихы. 90 еллар тарихы. 2000 еллар тарихы. 2010 еллар тарихы. 2020 еллар тарихы.Телеграммканал төзү.
Республика, район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.
Данлы укучылар
**Теория:** 30 еллар укучылары. 40 еллар укучылары. 50 еллар укучылары. 70 еллар укучылары 80 еллар укучылары. 90 еллар укучылары. 2000 еллар укучылары. 2010 еллар укучылары. 2020 еллар укучылары.Телеграммканал төзү.
**Практика:** 30 еллар укучылары. 40 еллар укучылары. 50 еллар укучылары. 70 еллар укучылары 80 еллар укучылары. 90 еллар укучылары. 2000 еллар укучылары. 2010 еллар укучылары. 2020 еллар укучылары.Телеграммканал төзү.
**Мөгаллим профессиясен сайлаган укучыларыбыз**
**Теория:** Мөгаллим профессиясен сайлаган укучыларыбыз. 50-70 еллар чыгарылышлары. 70-90 еллар чыгарылышлары. 90-2000 еллар чыгарылышлары. 2000-2005 еллар чыгарылышлары. 2005-2010 еллар чыгарылышлары. 2010-2020 еллар чыгарылышлары. Дәүләт бүләкләренә ия булган укучыларыбыз.

**Практика:** Мөгаллим профессиясен сайлаган укучыларыбыз. 50-70 еллар чыгарылышлары. 70-90 еллар чыгарылышлары. 90-2000 еллар чыгарылышлары. 2000-2005 еллар чыгарылышлары. 2005-2010 еллар чыгарылышлары. 2010-2020 еллар чыгарылышлары. Дәүләт бүләкләренә ия булган укучыларыбыз. Телеграммканал төзү. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

## 4 нче бүлек. Планлаштырылган нәтиҗәләр

Бу программа балаларның түгәрәк эшчәнлеге белән кызыксынуларын арттырыр, активлыкларын үстерер, тәрбия эшендәге эзлеклелек һәм дәвамчанлыкны тәэмин итәр, белем дәрәҗәләрен, иҗади сәләтләрен үстерергә этәргеч бирер. Программаның һәр бүлегендә алынган максатчан юнәлешле эшләр укучыларга үткәннәр белән кызыксыну, белемнәрен арттыру, эшне оештыру өчен һәм киләчәк тормышларында юнәлеш бирер өчен мөмкинлекләр бирер. Түгәрәктә укучыларның һәр адымында үз җаваплылыгын тоеп, үткәннәр белән горурланып, туган ягыбыз тарихын, мәдәниятен, халкын, көнкүрешен өйрәнү, мөстәкыйльлек, сәләте буенча иҗади хезмәтен оештырырга, әхлакый, сәламәт, туган ягын, аның табигатен яратучы, саклаучы игелекле шәхес булып үсәргә, баланың үз мөмкинлекләрен үзенең гамәлгә ашыруына ирешергә тәрбияви юнәлеш бирә. Шунлыктан бу программа белән эшләү күпкә уңайлы һәм нәтиҗәле булачак.Чөнки программа балаларга аңлаешлы, көчләре җитәрдәй эшләрне үз эченә ала. Кыскасы укучы үзен чын гражданин, җәмгыятебез өчен үзен кирәкле, файдалы шәхес, борынгы бабаларыбыз үрнәгендә, алар кылган игелекле эшләрне үзенә үрнәк итеп алып, туган ягыбызның шәфкатьле, горур милләтле татар баласы итеп тоячак. Туган ягын, халкын яратачак, аның гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итәчәк, үзе башкарып чыккан гамәлләре, иҗади эшләре белән горурланачак, биеклекләр яулаячак.

**Беренче уку елында укучыларда формалаштырылырга тиешле белем:**
Үз нәселеңнең, мәктәбеңнең, авылыңның тарихын белү;
Музей фондындагы экспонатлар турындагы мәгълүматка ия булу;
Бөек Ватан сугышының авылдашлар, авыл язмышына китергән афәте;
Үз районың һәм республиканың үсеше турында белү.
**Беренче уку елы азагына формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**
укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага сала белү;
тарихи вакыйгаларны аңлый һәм дөрес кабул итә белү;
материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый белү;
үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертә белү.
**Икенче уку елында укучыларда формалаштырылырга тиешле белем:**
1.Үз төбәгеңнең тарихын белү;
2.Музей фондындагы экспонатлар турындагы мәгълүматка ия булу;
3.Төбәгең һәм республиканың үсеше турында белү;
4. Азнакай районыннан чыккан язучылар, шагыйрьләр турындагы мәгълүматка ия булу;
**Икенче уку елының азагына формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**
1.Укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага сала белү;
2.Тарихи вакыйгаларны аңлый һәм дөрес кабул итә белү;
3. Материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый белү;

4.Үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертә белү.

**Өченче уку елында укучыларда формалаштырылырга тиешле белем:**

1. Нәселең шәҗәрәсе тарихын белү;
2. Музей фондындагы экспонатлар турындагы мәгълүматка ия булу;
3. Нәселең, төбәгең һәм республиканың үсеше турында белү;
4. Авылдаш язучыбыз Г. Галиев иҗаты турында, Азнакай районыннан чыккан язучылар, шагыйрьләр турындагы мәгълүматка ия булу;

**Өченче ук елының азагына формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

1.Укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага сала белү;
2.Тарихи вакыйгаларны аңлый һәм дөрес кабул итә белү;
3. Материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый белү;
4.Үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертә белү.

**Дүртенче уку елында укучыларда формалаштырылырга тиешле белем:**

1. Урманай урта мәктәбенең тарихын белү;
2. Музей фондындагы экспонатлар турындагы мәгълүматка ия булу;
3.Төбәгең һәм республиканың үсеше турында белү;
4. Урманай урта мәктәбеннән чыккан данлы кешеләр турындагы мәгълүматка ия булу;

**Дүртенче ук елының азагына формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

1.Укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага сала белү;
2.Тарихи вакыйгаларны аңлый һәм дөрес кабул итә белү;
3. Материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый белү;
4.Үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертә белү.

## 5 нче бүлек. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары

**Тормышка ашыру шартлары:** таләпләргә туры килеп яктыртылган укыту кабинеты, укытучы өстәле белән урындыгы, укучылар өчен өстәлләр белән урындыклар, класс тактасы, мәктәп музее кабинеты, ноутбук, **“**Әдәби мирас**”** өстәмә гомуми белем бирү гомуми үсеш программасы, югары педагогик белемле педагог.

**Методик материал**: “Әдәби мирас” өстәмә гомуми белем бирү гомуми үсеш программасы, фотосурәтләр, фотоальбомнар, музейда тупланган альбомнар, китаплар, истәлекләр, экспонатлар, карталар, әдәби китаплар, видеоязмалар, журналлар.

## 6 нче бүлек.
## Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары

**Аттестация формалары**: күзәтү, практик эш, мөстәкыйль эш, бәйге, әдәби – музыкаль кичә.
**Укыту нәтиҗәләре** видеоязма, иҗади эш, диплом, фотосурәт, фоторепортаж, презентация, эзләнү эше, проект яклау, әзер эш аша билгеләнә.
Укыту нәтиҗәләрен фәнни-практик конференциядә катнашу, иҗади эш яклауда, күргәзмәда, конкурста, бәйрәмдә күреп була.

**Аттестация материаллары** кушымтада бирелгән.
**Укыту алымнары**: күрсәтмә практик, өлешчә-эзләнү, аңлатма-иллюстратив, эзләнүле, уен, проект төзү.
**Белем бирү процессын оештыру формалары**: индивидуаль-төркемнәр белән эш һәм төркемнәрдә эш.
**Дәресләрне үткәрү формалары һәм төрләре:** практик, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр, интеллектуаль уеннар, эзләнү – тикшеренү эшләре, экскурсияләр, әдәби кичәләр, әңгәмә, индивидуаль консультацияләр, түгәрәк өстәл, дәрес-презентация, викторина, КВН, сәяхәт-дәрес, бәйгеләр, музейларга экскурсия, укучыларның әдәбият белән мөстәкыйль эше.
Укучыларда кызыксыну уяту өчен һәр дәрестә иҗадилык һәм эзләнү элементларын кертү.Теоретик һәм практик дәресләрне чиратлаштыру.

**Педагогик технологияләр**:
- үстерелешле укыту;
- хезмәттәшлеккә корылган укыту технологиясе;
- коммуникатив технологияләр;
- проблемалы һәм өлешчә эзләнү технологияләре;

Педагогик технологияләр һәм методларны сайлау укучының шәхси сыйфатлары һәм универсаль уку күнекмәләрен үстерү максатыннан укытуны дифференциальләштерү һәм индивидуальләштерү кирәклегеннән чыгып билгеләнде.
**Дәресләрнең алгоритмы.** Укыту дәресенең алгоритмы-этаплар саны аның тибына һәм белем бирү процессының урынына, шулай ук педагог сайлаган урынга, үткәрү формасына бәйле. Әлеге программа кысаларында нигездә уку дәресенең 10 этабы кулланылырга мөмкин:
Оештыру этабы;
Тикшерү этабы;
Әзерлек этабы;
Белемнәрне актуальләштерү этабы;
Яңа материал буенча эш этабы;
Алынган белемнәрне, күнекмәләрен беренчел беркетү этабы,
Өйрәнелгән материалны кабатлау этабы;
Үткән материалны гомумиләштерү этабы;
Яңа белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту этабы;

Физкультминутка яки релаксация этабы;
Контроль этап;
Йомгаклау этабы;
Рефлексия этабы;
Мәгълүмат этабы.

**Дидактик материалы**

Татар язучылары һәм шагыйрьләренең фоторәсемнәре – 2 шт, альбомы – 3 шт.

## 7 нче бүлек. Әдәбият исемлеге:

## Программа төзү өчен кулланган әдәбият исемлеге:


1. Краеведение в школе. – Педагогическая энциклопедия, т.2.М., Советская энциклопедия,1965, с. 518-520.

2. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.

3. В.Е.Туманов. Школьный музей-хранитель народной памяти.М., 2006.

4. Экология һәм табигатьтән файдалану. – 3 нче чыгарылыш. – Казан: Татполиграф, 1997. – 378 б.

5. А.С.Тайсин. Татарстан Республикасы географиясе. Гомуми урта белем мәктәбенең 8-9 класслары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел. – 230 б.


## Педагог өчен әдәбият исемлеге:


1. “Азнакай тамчылары” – Казан: “Рухият” нәшрияты, 2000 ел. – 210 б.

2. Азнакай районы Урманай урта мәктәбе  укучыларының мәдәният көндәлеге.

3. “Азнакай”. – Казан: “Эксклюзив” нәшрияты, 2001. – 171 б.

4. Большая Советская Энциклопедия. – третье издание. – Москва: Издательство “Советская энциклопедия”, 1972. – стр. 606

5. Книга памяти о советских воинах, погибших в Афганистане.-т-2, Москва, Военное издательство, 1999

6. “Мәйдан “журналлары

7.”Мәгариф”журналлары

8. Музей материаллары.

9.Татарстан тарихы.Төп мәктәп өчен уку әсбабы.-Казан.-ТаРИХ, 2001
10.Хәтер.Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы нәшр.,1996.

11. Красная книга Республики Татарстан. – К., 1995.

12. “Бай тарихлы Урманай”-Казан, “Идел -Пресс”, 2018


## Кулланылган интернет-чыганаклар


http://gzalilova.narod.ru

http://www.tatmedia.ru/

http://sabantui.com

http://kitaphane/tatarstan.ru/

http://tatmuzeum.ru/

В данном документе
пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью
19 (девятнадцать) листов
Директор Хасанова Р.М.
Подпись: